**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «23» нче мартыннан № 62

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә эшләүче, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбенә акча түләү тәртибен раслау турында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләр-хезмәткәрләренә акча түләүләр билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 7 мартындагы 127 номерлы карарын үтәү, Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә эшләүче, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбенә акча түләү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә Татарстан Республикасы спорт министрлыгы белән ел саен «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем учреждениесе хезмәткәрләренә-яшь белгечләргә акчалата түләүләр турында» Килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https:///pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбенә акча түләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 20 гыйнварындагы 15 номерлы;

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбенә акча түләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 20 гыйнварындагы 15 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбенә акча түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 31.05.2021 елның 31 маендагы 238 номерлы.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Башкарма комитетының
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «23» мартындагы
62 номерлы карары белән
расланган

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә эшләүче, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбенә акча түләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - район Башкарма комитеты) башкаручы, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә (алга таба - Оешма) эшләүче яшь белгечләргә-хезмәткәрләргә түбәндәге акчалата түләүләрне бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

эшләнгән вакытына пропорциональ 2510 сум күләмендә айлык стимуллаштыручы өстәмә;

хуҗалыкны төзекләндерүгә бер тапкыр түләнә торган 100 000 сум күләмендә акчалата түләү.

Оешманың координаторы булып район Башкарма комитетының функциональ органы - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (алга таба - Бүлек) тора.

2. Оешма хезмәткәренә-яшь белгечләренә акчалата түләүләр Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына (алга таба - Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районына тиешле финанс елына каралган акчалар хисабына башкарыла.

3. Оешма хезмәткәре - яшь белгече дип Россия Федерациясе гражданы танила, көндезге формада югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура программалары (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яисә югары белем бирү мәгариф оешмасы)буенча дәүләт аккредитациясе булган һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү оешмасын тәмамлаган, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә оешмага хезмәт шартнамәсе буенча һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча физкультура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренировкалар процессы администраторы,

адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы вазыйфасына эшкә алынган 35 яшькә кадәрге (35 яшьне дә кертеп) граждан санала.

4. Хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү аны эшкә алган айдан соң килгән айның 1 числосыннан билгеләнә һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләү шарты белән аны билгеләү датасыннан соң өч ел дәвамында түләнә.

Яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар район Башкарма комитет карары белән раслана.

Хезмәткәләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү чоры түбәндәге очракларда озайтыла:

Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте башкарганда;

йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, балага 3 яшь тулганчыга кадәр тәрбияләү өчен отпуск;

аспирантурада көндезге формада уку вактында.

5. Хезмәткәр – яшь белгеч башка оешмага, әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән вазифа башкаруга күчкәндә, эштән туктап тору вакыты 30 көннән дә артмаска тиеш.

6. Штат саны кимү яки штат кыскару белән бәйле рәвештә хезмәткәр – яшь белгеч эштән азат ителгән һәм алга таба башка оешмага әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән вазифага эшкә урнашкан очракта эштән туктап тору вакыты 60 көннән дә артмаска тиеш.

7. Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү төп хезмәт урыны буенча һәм әлеге хезмәткәр – яшь белгеч тарафыннан бер оешмада ике эшне башкару шартларында гамәлгә ашырылган вазыйфа буенча, ләкин 1 ставкадан артмаган күләмдә билгеләнә.

9. Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

биредә:

D - хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, сум;

P - хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә аена 2510 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

хезмәткәр-яшь белгеч тарафыннан эшләнгән сәгатьләрнең факттагы саны, сәгать;

спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешма хезмәткәрләренең төп хезмәт хакы ставкасы өчен сәгать нормасы, сәгатьләр.

10. Хуҗалык төзекләндерүгә түләнә торган акчалата түләү хезмәткәргә бер тапкыр гына бирелә.

Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә хуҗалык эшләре өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү, саклау, туктату турында карар Оешма боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Хезмәткәрләр - яшь белгечләрне хуҗалык белән тәэмин итүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алу хокукы, Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт иткән яки альтернатив граждан хезмәте вакытында саклана. Бу хокук, чакырылыш буенча хәрби хезмәттән яки альтернатив граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң өч айдан соңга калмыйча эшкә урнашу шарты белән тәэмин ителә.

11. Хезмәткәр оешма җитәкчесе исеменә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, хуҗалык эшләре өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза белән һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң эшкә урнашкан оешмада ике ел эшләү дәвамында мөрәҗәгать итә.

12. Хезмәткәрнең хуҗалык эшләре өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алу шарты булып, һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң төп эш урыны буенча ике ел дәвамында эшләү шарты тора.

Хезмәт килешүе туктатылган очракта, эшкә алган көннән соң ике ел вакыт үткәнчегә кадәр, ул әлеге срок тәмамланганчы фактта эшләнмәгән вакытка пропорциональ рәвештә билгеләнгән күләмдә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өлешен кире кайтарырга тиеш.

13. Бүлек ай саен, агымдагы елның 5 числосына кадәр, Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акча бирү турында гариза;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча төзелгән, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләр реестры.

14. Оешмада эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен район Башкарма комитеты чыгымнарының финанс белән тәэмин ителеше, Министрлык тарафыннан субсидия бирү юлы аша тормышка ашырыла. Субсидия, Министрлык белән район Башкарма комитеты арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк формага нигезләнеп төзелгән килешү (алга таба – Килешү) нигезендә бирелә.

Килешү әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң 10 көн эчендә төзелә.

15. Хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга субсидия Министрлык тарафыннан ай саен район Башкарма комитетының шәхси счетына күчерелә.

16. Бүлек, Килешүдә каралган сроклар һәм форма нигезендә, яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләрдән файдалану турында Министрлыкка хисап бирә.

17. Агымдагы финанс елында район Башкарма комитеты тарафыннан файдаланылмаган субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

18. Район Башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, Министрлыкның язма таләбе нигезендә субсидияләр тиешле таләп алынган көннән соң 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

19. Район Башкарма комитеты хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне законнарда билгеләнгән хезмәт хакын түләү вакытында бирүне тәэмин итә.